**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлегенең Кошман торак пунктында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**«24» ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 17 ноябрендә 09 сәгатьтә, 2023 елның 17 ноябрендә 13 сәгатьтә, 2023 елның 20 ноябрендә 09 сәгатьтә, 2023 елның 21 ноябрендә 10 сәгатьтә, 2023 елның 22 ноябрендә 14 сәгатьтә, 2023 елның 24 ноябрендә 13 сәгатьтә булган гражданнар җыеннары нәтиҗәсе белән «Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Кошман торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт территориясендә авария хәлендәге агачларны кисү һәм чыгару;

- торак пункт территориясен карап тоту;

- балалар мәйданчыгы урнаштыру, моның өчен материаллар сатып алу;

б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- су башняларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, моның өчен материаллар сатып алу;

в)авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 534 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 279, бу 52,25 % тәшкил итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 279 катнашучы тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең Кошман торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлеге Кошман торак пункты территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә караган түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

-урамны яктыртучы утларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт территориясендә авария хәлендәге агачларны кисү һәм чыгару;

- торак пункт территориясен карап тоту;

- балалар мәйданчыгы урнаштыру, моның өчен материаллар сатып алу;

б)авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- су башняларын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү, моның өчен материаллар сатып алу;

в)авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кошман авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә» – кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кошман авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кошман авыл җирлеге Башлыгы Л.Р.Сафина